**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **14ноябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Карамалы-Елга авылында 2026 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1,2 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларынан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, үләнне чаптыру, куакларны кисү, чүп җыю);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сәйдәшев урамындагы вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, Сәйдәшев урамындагы юлны профильләштерү);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.